# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Олы Битаман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 ел, 13 ноябрь №4

“Росиия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына белән 2024 елның 13 ноябрендә 18 сәгать 00 мунутта “Сез ризамы?:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Олы Битаман торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан һәм өлешчә мобилизация чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары һәм контракт буенча СВО да хезмәт итүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 ( биш йөз) сум күләмендә үз-үзенә салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
   1) халык яшәгән территорияне яхшырту (балалар мәйданчыгын яхшырту (балалар уен мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру, уен мәйданчыгы территориясенең куркынычсызлыгын тәэмин итү, материаллар, бизәкле үсемлекләр сатып алу);
   2) торак пункты чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (авыл эчендәге юлларны кыш һәм җәйге хезмәт күрсәтү (кардан урамнарны чистарту, трактор йөртүчесе хезмәт хакы, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу)

3) каты муниципаль калдыклар өчен саклау зоналарын урнаштыру, каты муниципаль калдыклар җыю өчен контейнерлар алу, рөхсәтсез полигоннарны бетерү (полигонны бетерү)

4) торак пункт юлларын ремонтлау, җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын тоту (ватылгнан таш сатып алу)

5) торак пункт территориясен яхшырту

“РИЗА” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 423 (дүрт йөз егерме өч) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 224 (ике йөз егерме дүрт) кеше, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленгән: гражданнар җыенында катнашучы 224 (ике йөз егерме дүрт) “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирә; җыенда катнашучы 0 (ноль) “КАРШЫ” позициясе өчен тавыш бирә. Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Олы Битаман торак пунктында узган гражданнар җыенын танырга, җыен нәтиҗәләрен гамәлдә дип санарга.
2. 2025 елда татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими рәвештә авыл территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан һәм өлешчә мобилизация чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары һәм контракт буенча СВО да хезмәт итүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 ( биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.
3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) халык яшәгән территорияне яхшырту (балалар мәйданчыгын яхшырту (балалар уен мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру, уен мәйданчыгы территориясенең куркынычсызлыгын тәэмин итү, материаллар, бизәкле үсемлекләр сатып алу);

2) торак пункты чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (авыл эчендәге юлларны кыш һәм җәйге хезмәт күрсәтү (кардан урамнарны чистарту, трактор йөртүчесе хезмәт хакы, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу)

3) каты муниципаль калдыклар өчен саклау зоналарын урнаштыру, каты муниципаль калдыклар җыю өчен контейнерлар алу, рөхсәтсез полигоннарны бетерү (полигонны бетерү)

4) торак пункт юлларын ремонтлау, җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын тоту (ватылгнан таш сатып алу)

5) торак пункт территориясен яхшырту

4. 2025 елда үзара салым түләүдән азат итәргә:

а) 1 төркем инвалидлар

б) өлешчә мобилизация чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, контракт буенча СВО да хезмәт итүчеләр һәм аларның гаилә әгъзалары

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муницпаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыен рәисе Г.Н.Сафина